ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
10.08.2026

Зеленодольск
шәһәре

КАРАР
№ 2743

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү тәртибен раслау турында

1994 елның 21 декабрендәге "Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 68-ФЗ номерлы Федераль законның 11 ст. 2 п. "п" пунктчасы , 2003 елның 06 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2019 елның 28 декабрендәге "Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фонды бюджет ассигнованиеләре торган федераль бюджеттан табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча аерым чараларны финанс белән тәэмин итүгә, террорчылык акты һәм зыянны каплау, террорчылык актын хокукый гамәлләр белән чикләгәндә китерелгән нәтиҗәдә зыян күргән физик һәм юридик затларга компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында" 1928 номерлы РФ Хөкүмәте карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү тәртибен 1 нче кушымтада каралганча расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү комиссиясе турында нигезләмәне 2 нче кушымтада каралганча расларга.
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр

нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү комиссиясе составын 3 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

4. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 10 августындагы
2743 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү тәртибе (алга таба – Тәртип), 1994 елның 21 декабрендәге «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 68-ФЗ номерлы Федераль законы белән билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатында эшләнгән.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән комиссия төзелә, аның кимендә өч кешедән торган составы һәм комиссиянең эш тәртибе раслана.

3. Комиссиянең эшне башлау өчен нигез – Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы исеменә килгән гражданиннарның табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә мал-мөлкәтләрен югалту нәтиҗәсендә беренче чиратта кирәк-ярак белән бәйле рәвештә финанс ярдәме күрсәтүне билгеләү турындагы гаризасы яки табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл чыганагының зарарлы факторлары тәэсире нәтиҗәсендә тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу белән бәйле рәвештә бер тапкыр матди ярдәм күрсәтүне билгеләү турындагы гаризасы комиссиягә тапшырыла.

4.Комиссия эшенең нәтиҗәләре буенча комиссиянең тиешле бәяләмәсе төзелә, ул комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

## II. Гражданнарның гадәттән тыш хәл зонасындагы торак урыннарда яшәү фактын ачыклау

1. Гадәттән тыш хәл зонасында урнашкан торак биналарда 14 яшьтән өлкән гражданнарның яшәү факты Комиссия карары белән түбәндәге критерийлар нигезендә ачыклана:

а) граждан гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының тиешле идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә гадәттән тыш хәл зонасына эләккән торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән;

б) граждан гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының тиешле идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә гадәттән тыш хәл зонасына эләккән торак урынында булу урыны буенча теркәлгән;

в) гадәттән тыш хәл зонасына эләккән торак урынны арендалау шартнамәсе булу;

г) гадәттән тыш хәл зонасына эләккән торак урынга социаль наем шартнамәсе булу;

д) эш яисә уку урыныннан белешмәләр, медицина оешмаларыннан белешмәләр булу;

е) медицина, мәгариф, социаль хезмәтләр күрсәтүне һәм почта элемтәсе хезмәтләре күрсәтүне расլый торган документлар булу;

ж) граждан тарафыннан инициатив тәртиптә тапшырылырга мөмкин булган, аларны алу өчен мөрәҗәгать итүчедән дәүләт (муниципаль) хезмәтләре, оешмалар хезмәтләре алу өчен мөрәҗәгать итүне таләп итмәгән, башка белешмәләр.

2. Комиссия тарафыннан 14 яшьтән өлкәнрәк гражданнарның гадәттән тыш хәл зонасындагы торак урыннарда яшәү фактларын ачыклау турында карар кабул итү өчен кирәкле тулы нигезләр, әлеге Тәртипнең II бүлегенең 1 пунктында күрсәтелгән белешмәләр буенча, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы белән билгеләнә.

3. 14 яшькә кадәрге балаларның гадәттән тыш хәл зонасындагы торак урыннарда яшәү факты, әгәр бала белән яши торган ата-ананың (уллыкка алучыларның, опекуннарның) берсе булса да гадәттән тыш хәл зонасындагы торак урында яшәү факты ачыкланган булса, комиссия карары белән билгеләнә.

## III. Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә гражданнарның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу фактларын ачыклау

1. Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә гражданнарның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу факты гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм билгеле бер территориядә кешеләрнең мал-мөлкәтләренә зыян килүгә, аларның гомеренә яки сәламәтлегенә куркыныч янауга бәйле рәвештә яшәп булмый торган хәлләрнең булуы яки булмавы белән билгеләнә.

2. Гражданнарның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартларының гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә бозылу факты комиссия карары белән түбәндәге критерийлар нигезендә билгеләнә:

а) гражданнарның торак урыннарда яшәргә мөмкин булмавы;

б) гражданнарның санитар-эпидемиологик иминлеге бозылу.

Гадәттән тыш хәл вакытында тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартларының бозылу факты, гражданнарның торак урыннарда яшәргә мөмкин булмавын характеристикалый торган күрсәтелгән критерийларның бер күрсәткече буенча гына да ачыклануы нигезендә билгеләнә.

2. Гражданнарның торак урыннарда яшәргә мөмкин булмавы критерие, торак урынның анда яшәү мөмкинлеген яки мөмкин түгеллеген характеристикалый торган түбәндәге торыш күрсәткечләре буенча бәяләнә:

а) бинаның (урынның) торышы;

б) бинаны (урынны)җылылык белән тәэмин итү торышы;

в) бинаны (урынны)су белән тәэмин итү торышы;

г) бинаны (урынны) электр белән тәэмин итү торышы;

Бина (урын) торышы визуаль рәвештә билгеләнә. Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә бинаның түбәндәге конструктив элементларының берсе булса да: фундаменты, стеналары, бүлемнәре, түшәмнәре, идәннәре, түбәсе, тәрәзәләре һәм

ишекләре, бизәү эшләре, мичләре, электр утлары зыян күрсә яки өлешчә җимерелсә, гражданның торак урында яшәү мөмкинлеге булмавы раслана.

Бинаны (урынны) җылылык белән тәэмин итүнең торышы инструменталь рәвештә билгеләнә. Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә гадәттән тыш хәлгә кадәр гамәлгә ашырыла торган торак бинаны (урынны) җылылык белән тәэмин итү бер тәүлектән артыграк туктатылса, гражданның торак урыннарда яшәү мөмкинлеге булмавы раслана.

Бинаны (урынны) су белән тәэмин итүнең торышы визуаль рәвештә билгеләнә. Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә гадәттән тыш хәлгә кадәр гамәлгә ашырыла торган торак бинаны (урынны) су белән тәэмин итү бер тәүлектән артык туктатылса, гражданның торак урыннарда яшәү мөмкинлеге булмавы раслана.

Бинаны (урынны) электр белән тәэмин итүнең торышы инструменталь рәвештә билгеләнә. Әгәр гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә гадәттән тыш хәлгә кадәр гамәлгә ашырыла торган торак бинаны (урынны) электр белән тәэмин итү бер тәүлектән артыграк туктатылса, гражданның торак урыннарда яшәү мөмкинлеге булмавы раслана.

3. Гражданнарның санитар-эпидемиологик иминлеге бозылу критерие инструменталь бәяләнә. Әгәр ул яшәгән районда гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә атмосфера һавасы, су, туфрак рөхсәт ителгән иң чик концентрациядән артып киткән пычраткыч матдәләр белән пычранса, гражданның санитар-эпидемиологик иминлеге бозылуы раслана.

## IV. Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә гражданнарның беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне югалту фактын ачыклау

1.Беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәт дигәндә кешенең сәламәтлеген саклау һәм аның тормыш-көнкүреш эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле гомумгаилә файдалануындагы азык-төлек булмаган товарларның минималь җыелмасы аңлашыла, ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:

а) азык-төлек саклау һәм әзерләү предметлары - суыткыч, газ плитәсе (электр плитәсе) һәм савыт-саба өчен шкаф;

б) ризык кабул итү өчен җиһаз предметлары - өстәл һәм урындык (табуретка);

в) йокы өчен җиһаз предметлары - карават (диван);

г) гражданнарга мәгълүмат бирү чаралары предметлары - телевизор (радио);

д) су белән тәэмин итү һәм җылыту чаралары предметлары (үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм җылыту булмаган очракта) - су бирү өчен насос, су җылыткыч һәм җылыту казаны (күчерелмә мич).

2. Беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтен югалту факты һәм дәрәҗәсе комиссия карары белән түбәндәге критерийлар нигезендә билгеләнә:

а) беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне өлешчә югалту-гадәттән тыш хәл чыганагының зарарлы факторлары йогынтысы нәтиҗәсендә гадәттән тыш хәл зонасына эләккән торак урындагы беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтнең бер өлеше (беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтнең кимендә 3 предметы) алга таба файдалану өчен яраксыз хәлгә килү;

б) беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне тулысынча югалту-гадәттән тыш хәл чыганагының зарарлы факторлары йогынтысы нәтиҗәсендә гадәттән тыш хәл зонасына эләккән торак урындагы барлык беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтнең алга таба файдалану өчен яраксыз хәлгә килү;

3. Беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтнең югалту дәрәҗәсен билгеләгәндә һәр категориянең беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәт предметларының бер тапкыр югалтуы исәпкә алына.

## V. Гражданнарның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне югалту сәбәпле бер тапкыр матди ярдәм һәм (яки) финанс ярдәме алу өчен исемлекләр әзерләү

1. Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне югалту сәбәпле бер тапкыр матди ярдәм һәм (яки) финанс ярдәме алу өчен гариза тапшыралар (тәкъдим ителгән формалар әлеге Тәртипкә 1 нче, 4 нче кушымталарда китерелде, вәкил яисә законлы вәкил гариза биргән очракта тәкъдим ителгән формалар әлеге Тәртипкә 2 нче, 5 нче кушымталарда китерелде).

2. Бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм алуга мохтаҗ гражданнар исемлекләре гражданнарның гаризалары һәм мөрәҗәгать итүченең гадәттән тыш хәл зонасындагы торак урында яшәү фактын һәм гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу фактын билгеләү турындагы комиссия бәяләмәләре (алга таба - яшәү һәм тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу фактларын билгеләү турындагы бәяләмә) нигезендә төзелә.

Яшәү фактларын һәм тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу фактларын билгеләү турындагы бәяләмә комиссия тарафыннан гадәттән тыш хәл зонасындагы бер торак урында яшәүче бер яисә берничә гражданга әзерләнергә мөмкин.

Бәяләмәгә комиссиянең барлык әгъзалары имза сала һәм, имзаның расшифровкасы белән дата куеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана һәм тиешле мөһер белән таныклана (тәкъдим ителгән формалар әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада китерелгән).

3. Беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне югалту сәбәпле финанс ярдәме алу өчен гражданнар исемлекләре гражданнарның гаризалары һәм һәм мөрәҗәгать итүченең гадәттән тыш хәл зонасындагы торак урында яшәү фактын һәм гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә беренче кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне югалту фактын билгеләү турындагы комиссия бәяләмәләрен (алга таба - яшәү һәм мөлкәтне югалту фактларын билгеләү турындагы бәяләмә) нигезендә төзелә.

Яшәү һәм мөлкәтне югалту фактларын билгеләү турындагы бәяләмә комиссия тарафыннан гадәттән тыш хәл зонасындагы бер торак урында яшәүче бер яисә берничә гражданга әзерләнергә мөмкин.

Бәяләмәгә комиссиянең барлык әгъзалары имза сала һәм, имзаның расшифровкасы белән дата куеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана һәм тиешле мөһер белән таныклана (тәкъдим ителгән формалар әлеге Тәртипкә 6 нчы кушымтада китерелгән).

4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, гражданнарның гадәттән тыш хәл зонасындагы торак урыннарда яшәү фактын, гражданнарның яшәү шартларын бозылу фактын һәм гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне югалту фактын билгеләү өлешендә, бер мәртәбә бирелә торган матди ярдәм алуга мохтаҗ гражданнар исемлекләренә һәм беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне югалтуга бәйле рәвештә финанс ярдәменә мохтаҗ гражданнар исемлекләренә имза сала. Финанс средстволары, тапшырылган исемлекләр нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан бүлеп бирелә.

5. Әлеге Тәртиптә каралган матди һәм финанс ярдәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән яисә мөлкәте югалган һәр торак урынга карата бер мәртәбә күрсәтелә.

## VI. Гаилә әгъзасы һәлак булуга (вафат булуга) бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган пособие алуга мохтаҗ гражданнар исемлекләрен (һәлак булган (вафат булган) гаилә әгъзасын күмүгә пособиеләрне дә кертеп), һәм сәламәтлеккә зыян килүгә бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган пособие алуга мохтаҗ гражданнар исемлекләрен әзерләү

1. Һәлак булган (вафат булган) гражданның гаилә әгъзалары Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә бер тапкыр бирелә торган пособие түләүне билгеләү турында гариза тапшыралар (тәкъдим ителә торган форма әлеге Тәртипкә 7 нче кушымтада китерелә, гариза вәкил яисә законлы вәкил тарафыннан бирелгән очракта тәкъдим ителә торган форма әлеге Тәртипкә 8 нче кушымтада китерелә).

2. Гаилә әгъзасы һәлак булуга (вафат булуга) бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган пособие алуга мохтаҗ гражданнар исемлекләре(һәлак булган (вафат булган) гаилә әгъзасын күмүгә пособиене дә кертеп) (алга таба - һәлак булуга (үлемгә) бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган пособие исемлекләре) гражданнар гаризалары һәм гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булу (вафат булу) фактын раслаучы тикшерүче (сорау алучы, судья) карарлары яисә суд билгеләмәләре нигезендә төзелә.

3. Сәламәтлеге зыян күргән гражданнар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гариза тапшыралар (тәкъдим ителә торган форма әлеге Тәртипкә 9 нчы кушымтада китерелә, гариза вәкил яисә законлы вәкил тарафыннан бирелгән очракта тәкъдим ителә торган форма әлеге Тәртипкә 10 нчы кушымтада китерелә).

4. Сәламәтлеккә зыян килүгә бәйле бер тапкыр бирелә торган пособие алуга мохтаҗ гражданнар исемлекләре (алга таба - сәламәтлеккә зыян килүгә бәйле бер тапкыр бирелә торган пособие исемлекләре) гражданнар гаризалары , гражданнарны гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм сәламәтлеккә зыян күргән дип тану турында тикшерүче (сорау алучы, судья) карары яки суд билгеләмәсе һәм зыян күрү авырлыгы дәрәҗәсе турында мәгълүмат нигезендә төзелә.

5.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәлак булуга (вафат булуга) бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган пособие исемлекләренә һәм сәламәтлеккә зыян килүгә бәйле бер тапкыр бирелә торган пособие исемлекләренә имза сала һәм аларны Татарстан Республикасы субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына җибәрә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 10 августындагы
2743 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү комиссиясе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданиннарның гадәттән тыш хәл зонасындагы торак урыннарда яшәү, аларның тормыш-көнкүреш шартлары бозылу һәм беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне (тулысынча яки өлешчә) югалту фактларын билгеләү комиссиясе (алга таба - Комиссия) киңәшче орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәл булганда, 1994 елның 21 декабрендәге «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 68-ФЗ номерлы федераль закон белән билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен оештырылган.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан 2022 елның 03 мартындагы 2-4-71-7-11 номерлы карары белән расланган беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтне югалту сәбәпле бер тапкыр акчалата матди ярдәм һәм (яки) финанс ярдәме , гаилә әгъзасы һәлак булуга (вафат булуга) бәйле бер тапкыр бирелә торган пособиене (һәлак булган (вафат булган) гаилә әгъзасын җирләүгә пособиене дә кертеп) һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетергәндә сәламәтлеккә зыян килүгә бәйле бер тапкыр бирелә торган пособиене алуга мохтаҗ гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибе буенча методик тәкъдимнәргә таянып эш итә.

## II. Комиссия составы

1. Комиссия составы 3 нче кушымтада расланган.

2. Комиссия Комиссия рәисеннән, Комиссия рәисе урынбасарыннан, Комиссия әгъзаларыннан тора.

3. Комиссия составына структур бүлекчәләре (Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге, җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы (килешү буенча), Россия ЭЭМ һәм Россия ГХМ идарәсенең территориаль бүлекчәләре вәкилләре (килешү буенча) керә.

## III. Комиссиянең бурычлары һәм функцияләре

1. Комиссиянең бурычлары:

- Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның (алга таба – гражданнар) гадәттән тыш хәл (алга таба – ГТХ) зонасындагы торак урыннарда яшәү фактын билгеләү;

- гражданнарның ГТХ нәтиҗәсендә тормыш шартларын бозу фактын билгеләү;

- гражданнарның ГТХ нәтиҗәсендә беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтен югалту фактын билгеләү;

2. Комиссия функцияләре:

-ГТХ нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарның яшәү шартлары бозылуга һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтен югалтуга (тулысынча яисә өлешчә) бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү турындагы гаризаларын кабул итә һәм карый;

- гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең комплектлылыгын һәм тапшырылган документларга туры килүен тикшерә;

- гражданнарның ГТХ зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм ГТХ нәтиҗәсендә беренче чиратта кирәк-ярак булган мал- мөлкәтен югалту фактын билгели;

- гражданнарның ГТХ зонасындагы торак урында яшәү фактын һәм гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүченең тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу фактын билгеләү турында бәяләмә әзерли;

- гражданнарның ГТХ зонасындагы торак урында яшәү фактын һәм мөрәҗәгать итүченең гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтен югалту фактын билгеләү турында бәяләмә әзерли;

- ГТХ нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарның гаризалары буенча яшәү шартлары бозылуга һәм беренче чиратта кирәк-ярак булган мал-мөлкәтен югалтуга бәйле рәвештә финанс ярдәменә мохтаҗ гражданнарның исемлекләрен төзи.

## IV. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары

1. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- үз компетенциясе чикләрендә Комиссиягә караган мәсьәләләрне үз утырышларында карарга;

- Комиссия эшендә катнашу өчен ГТХ нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарны, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен, башка вазыйфаи затларны һәм белгечләрне җәлеп итәргә;

- үз утырышларында Комиссиянең төп бурычларына һәм функцияләренә караган мәсьәләләр буенча Комиссия әгъзаларын, ГТХ нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарны, шулай ук башка затларны тыңларга;

- үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча федераль башкарма власть органнарының территория органнарыннан, дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан, гражданнардан кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматны соратып алырга;

- үз компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итәргә.

2. Комиссия үз эшчәнлеген федераль һәм региональ законнар, муниципаль хокукый актлар һәм әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырырга тиеш.

## V. Комиссиянең эш тәртибе

1.Комиссия эшчәнлегенең төп формасы булып утырышлар, шул исәптән гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарның беренче чиратта кирәк-ярак булган зыян күргән мал- мөлкәте урнашкан урынга күчмә утырышлар тора.

2. Комиссия утырышын Комиссия рәисе, ул булмаганда - Комиссия рәисе урынбасары алып бара.

3. Утырышта Комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш хокукый була. Утырышта Комиссия әгъзасы булмаган очракта, карала торган мәсьәләләр буенча ул үз фикерен язма рәвештә тәкъдим итәргә хокуклы.

4. Бер тапкыр бирелә торган матди яисә финанс ярдәме билгеләү турындагы гаризаны Комиссия тарафыннан карау, әгәр мөрәҗәгать итүченең (гаризада күрсәтелгән затларның) гаризада күрсәтелгән торак урында яшәү фактын билгеләү һәм мөрәҗәгать итүченең (гаризада күрсәтелгән затларның) тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу фактын билгеләү мөмкинлеге булмаса яисә мөрәҗәгать итүченең (гаризада күрсәтелгән затларның) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә беренче чиратта кирәк-ярак булган мал- мөлкәтен югалту фактын билгеләү мөмкинлеге булмаса, туктатып торыла.

Комиссия мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр бирелә торган матди яисә финанс ярдәм билгеләү турындагы гаризаны карауны туктатып тору турында мөрәҗәгать итүчегә әлеге карар кабул ителгән көннән алып, аны туктатып тору нигезләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүче җитешмәгән белешмәләрне тапшырган вакытка кадәр 15 эш көне , әмма 30 эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә хәбәр итә.

Бер тапкыр бирелә торган матди яисә финанс ярдәме билгеләү турындагы йә бер тапкыр бирелә торган матди яисә финанс ярдәме билгеләүдән баш тарту турындагы карар Комиссия тарафыннан гариза теркәлгән көннән алып 15 эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә кабул ителә.

5. Комиссия секретаре:

- Комиссия утырышы башланганчы Комиссия утырышы көн тәртибе проектын әзерли һәм аны Комиссия рәисе белән, ә ул булмаганда - Комиссия рәисе урынбасары белән килештерә.
- Комиссия утырышлары материалларын формалаштыра, Комиссия утырышларына әзерлекне оештыра;
- утырышны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында Комиссия әгъзаларына хәбәр итә;
- Комиссия эшчәнлегенә бәйле материаллар тупланган архивны алып бара;

6. Комиссия карарлары үзенең утырышларында комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

7. Карар бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә, ул Комиссиянең утырышта булган барлык әгъзалары тарафыннан имзалана, Комиссия рәисе - Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

8. Комиссия карарларына карата гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә мөмкин.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 10 августындагы
2743 номерлы карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | **Бауэр Анастасия Сергеевна** (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, икътисадый үсеш) |
| Комиссия рәисе урынбасары | **Матвеева Ольга Александровна** (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары, торак сәясәте һәм аерым программаларны гамәлгә ашыру) |
| Комиссия секретаре | **Рәхимова Лилия Фәрит кызы** ("Зеленодольск муниципаль районы торак сәясәте департаменты" МБУ җитәкчесе урынбасары) |
| Комиссия әгъзалары: | **Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы авыл һәм шәһәр торак пунктлары Башлыклары (Башкарма комитетлар җитәкчеләре)** |
| Комиссия әгъзасы: | **Мәхмутов Ирик Абрахман улы** ("Зеленодольск муниципаль районы төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты" МБУ җитәкчесе) |
| Комиссия әгъзасы: | **Садриев Ленар Ринат улы** ("ТР Зеленодольск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалык департаменты" МБУ җитәкчесе) |
| Комиссия әгъзасы: | **Краснобаев Евгений Васильевич** (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, көч структуралары белән үзара хезмәттәшлек, административ практика |
| Комиссия әгъзасы: | **Нигъмәтуллин Динар Азат улы**(Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, социаль мәсьәләләр) |
| Комиссия әгъзасы: | **Алексахина Анна Юрьевна** ("Зеленодольск муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МУ җитәкчесе) килешү буенча |
| Комиссия әгъзасы: | **Дёгтева Ольга Павловна** ("Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы" МУ җитәкчесе) килешү буенча |
| Комиссия әгъзасы: | **Камалов Данис Линар улы**(Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Зеленодольск муниципаль районында бүлекчә полициясе начальнигы урынбасары ) – килешү буенча |
| Комиссия әгъзасы: | **Мөхәмәдҗанов Эдуард Илсур улы** (ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең сигезенче янгын сүндерү-коткару отряды начальнигы) – килешү буенча |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү тәртибенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенә

_______________________________________

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

кемнән: _______________________________________

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

**ГАРИЗА**

Миңа,

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, шәхесен раслаучы документ мәгълүматлары, яшәү урыны адресы)*

гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм ярдәм билгеләвегезне сорыйм.

____________________________________________________________

____________________________________________________________

*(тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу сәбәбе)*

____________________________________________________________

____________________________________________________________

_*(тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу датасы)*

____________________________________________________________

_____ _______________________________________________________

*(түләү ысулы күрсәтелә : кредит оешмалары аша яки почта элемтәсе оешмасы аша)*

Мөрәҗәгать итүченең контакт мәгълүматлары:
Телефоны: ___________________________________
Түләү өчен банк реквизитлары:
Исәп-хисап счеты: ____________________________
Банк исеме: ________________________
БИК _____________________________________
ИНН _____________________________________
КПП _____________________________________
Банк картасы номеры _____________________
«______»____________ ел ________________ ______________________
*(дата)* *(имза) (фамилиясе, инициаллары)*

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге гаризада һәм теркәп бирелә торган документларда күрсәтелгән белешмәләрне эшкәртүгә (җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, төгәлләштерүгә, куллануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрне бетерергә, блоклауга, юкка чыгаруга) ризалык бирәм. Миңа әлеге ризалыгым минем тарафтан кире алынырга мөмкин, дип аңлаттылар.

«______»____________ ел _______________ ______________________
*(дата)* *(имза)* *(фамилиясе, инициаллары)*

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә гражданнарның гадәттән тыш хәлләр зонасындагы торак урыннарында яшәү, аларның тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу һәм мал-мөлкәтләрен югалту фактларын билгеләү тәртибенә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенә

_______________________________________

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

_______________________________________

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

**ГАРИЗА**

Миңа, балигъ булмаган яисә хокукка сәләтсез затның вәкиленә һәм (яисә) законлы вәкиленә_________________________________________________________________________

______________________________________________________________________,

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, шәхесне таныклаучы документ күрсәткечләре, яшәү урыны адресы, вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ күрсәткечләре)*

______________________________________________________________________

гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартларын бозылуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түләү билгеләвегезне сорыйм.

______________________________________________________________________

*(тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу сәбәбе)* _

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________,

*(тормыш-көнкүреш эшчәнлеге шартлары бозылу датасы)*

минем балигъ булмаган балаларыма:

1.________________________________________________________________

2. ________________________________________________________________

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, туу турында таныклыгы (сериясе, номеры, датасы), туу турында акт язмасының датасы һәм номеры яисә чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән туу турында документның реквизитлары)*

мин вәкиле һәм (яисә) законлы вәкиле булган башка затлар:

1._
2.____________________________________________________________

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, шәхесне раслаучы документ мәгълүматлары)*

_________________________________________________________________

(түләү ысулы күрсәтелә : кредит оешмалары аша яки почта элемтәсе оешмасы аша)

Мөрәҗәгать итүченең контакт мәгълүматлары:
Телефоны: ____________________________________
Түләү өчен банк реквизитлары:
Исәп-хисап счеты: ____________________________
Банк исеме: _________________________
БИК ______________________________________
ИНН ______________________________________
КПП ______________________________________
Банк картасы номеры ______________________

«__»______________ ел ______________ ____________________
*(дата)* *(имза) (фамилиясе, инициаллары)*

